**Казан шәһәре Башкарма комитетының**
**2024 елның 29 ноябрендәге 4944 номерлы карары**

**Казан шәһәре Башкарма комитетының 2015 елның 6 апрелендәге 1724 номерлы «Казан шәһәре территориясендә стационар булмаган сезонлы сәүдә объектларын һәм җәмәгать туклануы объектларын урнаштыру схемаларын раслау турында»гы карарына үзгәрешләр кертү хакында**

2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы «Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында»гы, 2009 елның 28 декабрендәге 381-ФЗ номерлы «Россия Федерациясендә сәүдә эшчәнлеген дәүләт тарафыннан җайга салу нигезләре турында»гы федераль законнар, Казан шәһәре муниципаль берәмлеге Уставы, Казан шәһәре Башкарма комитетының 2013 елның 21 августындагы 7575 номерлы «Казан шәһәре территориясендә стационар булмаган сезонлы сәүдә объектларын һәм җәмәгать туклануы объектларын урнаштыру тәртибе хакындагы нигезләмәне раслау турында»гы карары нигезендә, халыкның товар сатып алу мөмкинлеген тәэмин итү максатыннан **карар бирәм**:

1. Казан шәһәре Башкарма комитетының 2015 елның 6 апрелендәге 1724 номерлы «Казан шәһәре территориясендә стационар булмаган сезонлы сәүдә объектларын һәм җәмәгать туклануы объектларын урнаштыру схемаларын раслау турында»гы карарының (аңа Казан шәһәре Башкарма комитетының 2017 елның 14 февралендәге 340 номерлы, 2017 елның 10 маендагы 1681 номерлы, 2017 елның 5 июнендәге 2093 номерлы, 2017 елның 15 июнендәге 2184 номерлы, 2017 елның 17 июлендәге 2651 номерлы, 2017 елның 29 ноябрендәге 4884 номерлы, 2018 елның 5 февралендәге 481 номерлы, 2018 елның 11 сентябрендәге 4859 номерлы, 2018 елның 2 ноябрендәге 5666 номерлы, 2019 елның 28 мартындагы 1011 номерлы, 2019 елның 5 июнендәге 2057 номерлы, 2020 елның 7 маендагы 1308 номерлы, 2020 елның 29 июлендәге 2057 номерлы, 2020 елның 29 октябрендәге 3051 номерлы, 2021 елның 16 апрелендәге 913 номерлы, 2021 елның 22 июнендәге 1546 номерлы, 2021 елның 3 сентябрендәге 2196 номерлы, 2021 елның 22 сентябрендәге 2379 номерлы, 2021 елның 22 сентябрендәге 2402 номерлы, 2022 елның 25 маендагы 1520 номерлы,

2022 елның 11 августындагы 2696 номерлы, 2023 елның 28 июлендәге 2136 номерлы, 2023 елның 29 августындагы 2457 номерлы, 2024 елның 27 апрелендәге 1687 номерлы карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) «Казан шәһәре территориясендә стационар җәмәгать туклануы объектлары каршында сезонлы кафелар урнаштыру схемасы» дигән 4 номерлы кушымтасына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. «Яңа Савин районы» бүлегенә түбәндәге эчтәлекле юл өстәргә:

| **Реестр номеры** | **Адресы, урнашу урыны** | **Мәйданы, кв.м** |
|---|---|---|
| **Яңа Савин районы** | | |
| «ЛВ-НС-31 | Чистай урамы, 20а | 55 кә кадәр» |

1.2. «Вахитов районы» бүлегенә түбәндәге эчтәлектәге юллар өстәргә:

| **Реестр номеры** | **Адресы, урнашу урыны** | **Мәйданы, кв.м** |
|---|---|---|
| **Вахитов районы** | | |
| «ЛВ-В-178 | К.Маркс ур., 27/11 | 30 га кадәр |
| ЛВ-В-179 | Ташаяк ур., 1 | 150 гә кадәр» |

1.3. «Идел буе районы» бүлегендә түбәндәге эчтәлекле юл өстәргә:

| **Реестр номеры** | **Адресы, урнашу урыны** | **Мәйданы, кв.м** |
|---|---|---|
| **Идел буе районы** | | |
| ЛВ-П-17 | Борисково ур., 68 | 340 ка кадәр» |

1.4. «Мәскәү районы» бүлегендә түбәндәге эчтәлекле юлларны төшереп калдырырга:

| **Реестр номеры** | **Адресы, урнашу урыны** | **Мәйданы, кв.м** |
|---|---|---|
| **Мәскәү районы** | | |
| «ЛВ-М-6 | Декабристлар ур., 131д | 40 ка кадәр» |
| «ЛВ-М-10 | Декабристлар ур., 83 | 20 гә кадәр» |

2. Әлеге карарны «Муниципаль хокукый актлар һәм башка рәсми мәгълүмат» челтәр басмасында (www.docskzn.ru) бастырырга, Казан шәһәре җирле үзидарә органнарының рәсми порталында (www.kzn.ru) һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (www.pravo.tatarstan.ru) урнаштырырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Казан шәһәре Башкарма комитеты Җитәкчесе урынбасары И.С.Шакировка йөкләргә.

**Җитәкче** **Р.Г.Гафаров**